# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге составына кергән Дәвек торак пунктында
халык җыены нәтиҗәләре турында

**17.11.2020ел.** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Дәвек торак пунктында халык җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Дәвек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (1, 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, БВС һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш) үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) Дәвек торак пунктында Советская урамында янгын сүндерү гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру – 2 данә 9эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

2) Дәвек торак пунктында юлларны грейдерлау (эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

3) Дәвек торак пунктында суэтем башнясының санитар саклау зонасында җиһазлау белән павильон монтажлау (эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

4)Дәвек торак пунктында суэтем башнясы территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, коймалар урнаштыру, капка кую, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

3. Әлеге карарны Тауасты Байлар авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру аша халыкка җиткерергә, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://menselinsk.tatarstan.ru).

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Минзәлә муниципаль районы**
**Тауасты Байлар авыл җирлеге Башлыгы**

**(имза)** **З.С.Гәрәева**
**(тулысынча имза)**